КИЛЕШЕНДЕ
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы

__________ Р.Н.Хузин
«___»__________ 2025 нче ел

РАСЛЫЙМ
Яр Чаллы шәһәренең “Шатлык” 1 нче балалар бакчасы- баланың аң- белемен үстерү үзәге муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире
__________ И.У.Гамманова
«___»__________ 2025 нче ел

**«Минем балам татарча сөйләшә»**
**төбәкара иҗади бәйгенең нигезләмәсе**

## 1. Гомуми нигезләмә.

1.1. Әлеге нигезләмә «Минем балам татарча сөйләшә» төбәкара балалар бәйгесен оештыру һәм үткәрү тәртибен, анда катнашу шартларын билгели.
1.2. Бәйге татар гаиләләренең милли үзаңын уяту, заманча мәдәни кыйммәтләрен, тарихи хәтерен, татар телен саклау, яклау һәм үстерү максатларында үткәрелә.
1.3. Бәйгене оештыручылар: Яр Чаллы шәһәре мәктәпкәчә учреждениеләрнең мәгариф идарәсе, Яр Чаллы шәһәренең “Шатлык” 1 нче балалар бакчасы- баланың аң- белемен үстерү үзәге муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе.

## 2. Бәйгенең максаты һәм бурычлары.

2.1 **Максат:** гаилә культурасын тәрбияләү һәм татар гаиләләрендә язма мирасыбыз хәзинәләре аша балаларның рухи, интеллектуаль һәм иҗади өлкәсен баету.
2.2.**Бурычлар:**
– Татар халкының гасырлар дәвамында фондларда, архивларда тупланып килгән фольклор мирасын иҗади гаиләләр аша дөньяга чыгару, энҗе бөртекләрен табу, барлау.
– Онытылып барган халык авыз иҗатын басма чыганаклардан күтәреп, хәтердә торгызып, тормышыбызга кире кайтару.
– Яшь буынны мили традицияләргә якынайту.
– Газета – журналларда милли яшәешебезне, рухи кыйммәтләребезне чагылдырган әсәрләргә мөрәҗәгать итү.

## 3. Бәйгене үткәрү шартлары һәм тәртибе.

3.1. Бәйге татар телендә үткәрелә.

3.2. Бәйгедә катнашу өчен 3 яшьтән алып 7 яшькәчә балалары булган иҗади гаиләләр чакырыла.
3.3. Катнашучы гаилә татар телендә гаилә традицияләре турында сөйли һәм **бала халык авыз иҗаты жанрындагы бер әсәрне башкара.** (Риваять, бәетләр, мәсәлләр, мәзәкләр, легендалар, бишек җырлары һ.б) Чыгыш вакыты: 3-5 минут.
Чыгыш вакытында музыкаль бизәлеш, костюмнар куллану рөхсәт ителә.
3.4. Катнашучының бәйге чыгышын (h264, mp 4, mpeg 2 форматында видеога яздырып, сылтама һәм заявка балалар бакчасының электрон почтасына җибәрергә кирәк. (Заявка формасы: Приложение 1)

## 4. Бәйгене бәяләү критерийлары.

4.1. Бәяләү критерийлары:
- гаилә әгъзаларының сөйләменең дөреслеге һәм чисталыгы;
- баланың әсәрне башкару осталыгы;
- игълан ителгән әсәрне белү;
- актерлык осталыгы;
- башкаручының сәхнә культурасы;

4.2. Бәйге эшләрен жюри 10 балл белән бәяли.

## 5. Бәйгене үткәрү вакыты һәм урыны.

**5.1.** Бәйгедә катнашу өчен заявкалар 2025 нче елның 14 нче февраленә кадәр бакчаның электрон почтасына madou001@mail.ru «Конкурска»дип язып җибәрелә.
5.3. **I этап- сайлап алу туры.** Видеофайлларны карау 2025 нче елның 17-18 февралендә үткәрелә.
5.4. **II этап- җиңүчеләрне билгеләү.** Бу турда иң күп балл җыйган гаиләләр 25 февраль көнне «Минем балам татарча сөйләшә» төбәкара иҗади бәйгесендә катнаша.
Үткәрү урыны һәм элемтәләр: Яр Чаллы шәһәренең “Шатлык” 1 нче балалар бакчасы- баланың аң- белемен үстерү үзәге муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, адресы буенча Муса Җәлил проспекты, 31нче йорт (ГЭС бистәсе, 4/23йорт).Телефон: 70-20-86

## 6. Йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү.

6.1. Бәйге эшләрен хөкемдарлар бәяли.
6.2. Бәйгенең II турда җиңүчеләре һәм призерлары 1 нче, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗәдәге дипломнар белән һәм «Салават күпере» журналының махсус призы белән бүләкләнә.
6.3. Хөкемдарлар составы оештыру комитеты тарафыннан формалаша.
6.4. Хөкемдарлар карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.
6.5. «Салават күпере» журналы конкурска мәгълүмати ярдәмне һәм конкурс нәтиҗәләрен журнал битләрендә күрсәтүне тәэмин итә.